РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а
тел. (84362)2-23-23

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер урамы, 19 а йорт
тел. (84362)2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
15.05.2023

КАРАР
№15

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 30 нчы апрелендә кабул ителгән 12 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү турында

Тимершык авыл җирлеге халкының саны үзгәрү сәбәпле, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» нең 30.04.2018 елгы №12 карарына (Советның 09.11.2018 №12, 09.11.2020 №12, 17.10.2022 №18, 19.12.2022 №25 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның кушымталарын әлеге карарга 1,2 нче кушымта итеп яңа редакциядә бәян итәргә.

1.2. Нигезләмәнең 2.3. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Җирлек башлыгына ай саен 0,8633 акчалата бүләк күләмендә акчалата бүләк түләнә.».

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән яңа штат расписаниеләрен расларга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә әлеге карарның гамәлдә булуын җәелдерергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча урнаштырырга.

Тимершык авыл
җирлеге башлыгы А.Х. Хаҗиев

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 маенда 15 номерлы карарына 1 нче кушымта

Коэффициентлар таблицасы, Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын исәпләгәндә кулланыла торган

| Вазыйфаларның исеме | Коэффициентлар |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 1,50 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (сәркатибе) | 1,47 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,11 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 1,00 |

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 маенда 15 номерлы карарына 2 нче кушымта

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаларның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 19039 |
| Депутатлар | 12688 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 12688 |